СОВЕТ
УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2021 № 25

Ульянково ав.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Советының 2015 елның 5 нче октябрьдәге 8 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге Советының 2015 елның 5 нче октябрьдәге 8 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) бюджет учреждениеләренең административ һәм офис биналарын, мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт, мәдәният, сәнгать объектлары урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,11 %.»;

1.1. 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. Салым ташламалары.

Җир салымын түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

- гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле оешмалар (урманнар, урман парклары, парклар, скверлар, шосселар, проспектлар, урамнар, тыкрыклар, мәйданчыклар, тукталышлар, һәйкәлләр, яр буе, колонкалар, су объектлары, су башнялары, чишмәләр, коелар, артезиан скважиналары астында);

- зиратлар, үләт базлары һәм гражданнар зиратлары урнашкан җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле оешмалар һәм учреждениеләр;

- Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аккредитация узган муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары администрацияләре;

- физик затлар - янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләре һәм әлеге статусны раслый торган документы булган ирекле янгын сүндерүчеләр.».

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://ulyan-kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Ульянково авыл жирлеге Башлыгы Сундурова Ф.А.